«Хуплыйм»

«Сәләт» проектлары җитәкчесе

________________Әдип Әлмир

«4» ноябрь 2024 ел

«Раслыйм»

«Сәләт» ТТЯФ

Генераль директоры

________________Э.Р. Насибуллина

«4» ноябрь 2024 ел

Сәләтле балаларны һәм яшьләрне үстерү өлкәсендә X республикакүләм «Сәмрух» ел премиясе

НИГЕЗЛӘМӘ

1. Премиянең оештыручылары.

Премия Татарстан төбәк «Сәлэт» (Талант) яшьләр фонды тарафыннан Татарстан Республикасы Хөкүмәте ярдәме белән үткәрелә.

2. Премиянең максаты һәм бурычлары.

Премиянең максаты: Сәләт хәрәкәтендә катнашучы сәләтле балаларны һәм талантлы яшьләрне бүләкләү, Сәләт активистларының, партнерларының, Сәләт проектлары авторларының һәм оештыручыларның эшенә бәя бирү.

Премиянең бурычлары:

- ел дәвамында Сәләт проектларында катнашып, Россиядә һәм чит илләрдә Татарстан исемен уңай яңгыратуга үз өлешләрен керткән сәләтле балаларны һәм мөгаллимнәрне бүләкләү;
- бүгенге җәмгыятьтә интеллект һәм рухны беренче урынга кую идеяләрен алга этәрү;
- прогрессив фикерләүгә, этник индивидуальлек һәм гомумкешелек сыйфатларына ия булган иҗади-интеллектуаль элита үстерүдә катнашу;
- Сәләт хәрәкәтендә катнашучы балаларда иҗади һәм иҗтимагый активлык дәрәҗәсен арттыру.

3. Премиядә катнашучылар.

Сәләтле балаларны һәм яшьләрне үстерү өлкәсендә республикакүләм «Сәмрух» ел премиясендә Сәләт хәрәкәтендә актив балалар, яшьләр, укытучылар катнаша.

Бер номинациядә җиңү яулаган катнашучы икенче елда шул ук номинациядә катнаша алмый.

Ярышта катнашучылар гаризаны 1 яки 2 номинациядә генә тапшыра алалар.

4. Премияне уздыру шартлары, тәртибе һәм вакыты.

Премия дүрт этапта уздырыла:

1 нче этап – «Гаризалар кабул итү».

Катнашучылар гаризаны расланган формада www.selet.biz сайтында тутыралар һәм портфолиоларын Оештыру комитетына җибәрәләр. Вакыты – **2024 елның 20 нче ноябренә** кадәр.

2 нче этап – «Катнашучыларны сайлап алу. Читтән торып катнашу этабы».

Катнашучыларны портфолио нигезендә сайлап алу. Премиянең Оештыру комитеты катнашучының гаризасын карый һәм аны түбәндә билгеләнгән критерийлар нигезендә бәяли. Катнашучының киләсе этапка узу-узмавы җыелган баллар санына карап билгеләнә. Игътибар! Барлык номинацияләрдә дә катнашучыларның **соңгы ике елда** ирешкән уңышларына бәя бирелә. Вакыты – **2024 ел, 24 нче ноябрь - 4 нче декабрь**.

3 нче этап – «Катнашучыларны әңгәмә нигезендә сайлап алу».

Кандидатлар белән әңгәмәне экспертлар советы уздыра һәм бәя бирә, аның төп максаты – катнашучының эшчәнлеге турында тулырак мәгълүмат алу. Катнашучының чыгышы нәтиҗәләре буенча экспертлар составы баллар куя. Алар беренче этап баллары белән кушыла. Биремнәрнең формасын һәм эчтәлеген экспертлар билгели. Экспертлар, нәтиҗә ясаганда, катнашучыларның читтән торып сайлап алу этабында туплаган балларын да исәпкә алырга хокуклы.

Конкурс уздырылуга 5 көн кала, уздырылу урыны, вакыты һәм конкурсның эчтәлеге хакында хәбәр ителә. Вакыты – **2024 елның 5 нче декабреннән 2025 елның 16 нчы гыйнварына кадәр**.

4 этап – «Тантаналы рәвештә премияне тапшыру».

**2025 ел, февраль** – лауреатларны һәм премиянең җиңүчеләрен бүләкләү. Тантананы үткәрү датасы һәм вакыты Оештыру комитеты тарафыннан өстәмә рәвештә хәбәр ителә. Көтелмәгән шартлар килеп чыккан очракта, Оештыру комитеты премиянең уздыру этапларын үзгәртергә мөмкин.

5. Премия номинацияләре һәм бәя бирү шартлары.

Сәләтле балаларны һәм яшьләрне үстерү өлкәсендә республикакүләм «Сәмрух» ел премиясе түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә:

**«Ел директоры» номинациясе.**

Номинациядә катнашу өчен мөһим шартлар:

- әлеге номинациядә 2024 елгы җәйге профильле «Сәләт» аланнарының директорлары катнаша ала (Кушымта 1).

Портфолионы бәяләү критерийлары:

- Сәләт берләшмәсе эшчәнлегендә актив катнашу;
- Сәләт берләшмәсендә казанышларга ия булу;
- шәхси һәм профессиональ уңышларга ия булу;
- фәнни-тикшеренү эшчәнлегендә, мәдәни һәм спорт чараларында, иҗтимагый эшчәнлектә казанышларга ия булу;
- эшчәнлекнең Сәләт җитәкчелеге, лагерь базасы җитәкчелеге тарафыннан бәяләнүе.

Икенче этапта экспертларның бәя бирү критерийлары:

1. «Үзпрезентация» конкурсы:

- презентациянең оригинальлеге;

- презентациянең эчтәлеге (презентациядә берләшмәнең эшчәнлегендә актив катнашу, берләшмә кысаларында һәм аннан тыш казанышлар, җитәкчелек тарафыннан эшчәнлекне бәяләү кебек моментларны чагылдыру);
- презентациянең төзеклеге: видео/фото материаллар, сценография;
- тамашачыларга мәгълүматны җиткерә белү сәләте;
- гомуми тәэсир;
- Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә дә сөйләшә белү;
- сменага кадәрге һәм сменадагы эшне оештыру (документлар, планлаштыру, балаларны җыю һәм сайлап алу);
- команда эшен формалаштыру һәм оештыру;
- кызыксынуы һәм катнашы булган яклар (партнерлар, ата-аналар, Сәләт җитәкчелеге, сменада катнашучылар) белән хезмәттәшлек.

Регламент: чыгыш ясау өчен 5 минут, сораулар өчен 3 минут.

2. «Педагогик очраклар» конкурсы:

- катлаулы педагогик һәм административ очраклар барлыкка килгәндә үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен аңлау.

**«Ел өлкән әйдаманы» номинациясе.**

Номинациядә катнашу өчен мөһим шартлар:

- әлеге номинациядә 2024 елгы җәйге профильле «Сәләт» аланнарының өлкән әйдаманнары катнаша ала (Кушымта 1).

Портфолионы бәяләү критерийлары:

- Сәләт берләшмәсе эшчәнлегендә актив катнашу;
- Сәләт берләшмәсендә казанышларга ия булу;
- шәхси һәм профессиональ уңышларга ия булу;
- фәнни-тикшеренү эшчәнлегендә, мәдәни һәм спорт чараларында, иҗтимагый эшчәнлектә казанышларга ия булу;
- эшчәнлекнең смена директоры, Сәләт җитәкчелеге, лагерь базасы җитәкчелеге, тарафыннан бәяләнүе.

Икенче этапта экспертларның бәя бирү критерийлары:

1. «Үзпрезентация» конкурсы:

- презентациянең оригинальлеге;
- презентациянең эчтәлеге (презентациядә берләшмәнең эшчәнлегендә актив катнашу, берләшмә кысаларында һәм аннан тыш казанышлар, җитәкчелек тарафыннан эшчәнлекне бәяләү кебек моментларны чагылдыру);
- презентациянең төзеклеге: видео/фото материаллар, сценография;
- тамашачыларга мәгълүматны җиткерә белү сәләте;
- гомуми тәэсир;
- Татарстан Республикасы дәүләт телләрен югары дәрәҗәдә белү;
- команда эшен формалаштыру һәм оештыру;
- сменаның укудан тыш программасы: төзү, оештыру һәм уздыру;
- программада Сәләт үзенчәлекләренең (татар теле, кыйммәтләр) чагылышы.

Регламент: чыгыш ясау өчен 5 минут, сораулар өчен 3 минут.

2. «Педагогик очраклар» конкурсы:

- катлаулы педагогик һәм административ очраклар барлыкка килгәндә үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен аңлау.

**«Ел методисты» номинациясе.**

Номинациядә катнашу өчен мөһим шартлар:

- әлеге номинациядә 2024 елгы җәйге профильле «Сәләт» аланнарының методистлары катнаша ала (Кушымта 1).

Портфолионы бәяләү критерийлары:

- Сәләт берләшмәсе эшчәнлегендә актив катнашу;
- Сәләт берләшмәсендә казанышларга ия булу;
- шәхси һәм профессиональ уңышларга ия булу;
- фәнни-тикшеренү эшчәнлегендә, мәдәни һәм спорт чараларында, иҗтимагый эшчәнлектә казанышларга ия булу;
- эшчәнлекнең смена директоры, Сәләт җитәкчелеге тарафыннан бәяләнүе.

Икенче этапта экспертларның бәя бирү критерийлары:

1. «Үзпрезентация» конкурсы:

- презентациянең оригинальлеге;
- презентациянең эчтәлеге (презентациядә берләшмәнең эшчәнлегендә актив катнашу, берләшмә кысаларында һәм аннан тыш казанышлар, җитәкчелек тарафыннан эшчәнлекне бәяләү кебек моментларны чагылдыру);
- презентациянең төзеклеге: видео/фото материаллар, сценография;
- тамашачыларга мәгълүматны җиткерә белү сәләте;
- гомуми тәэсир;
- Татарстан Республикасы дәүләт телләрен югары дәрәҗәдә белү;
- остазларны, партнерларны сайлап алу, аларның эшен формалаштыру һәм оештыру;
- Программаны проектлау һәм гамәлгә ашыру (максат, бурычлар, тормышка ашыру ысуллары, балаларны юнәлешләр буенча бүлү принцибы, аларны бәяләү нәтиҗәләре һәм ысуллары, смена профиленә туры килү);
- программада Сәләт үзенчәлекләренең (татар теле, кыйммәтләр) чагылышы.

Регламент: чыгыш ясау өчен 5 минут, сораулар өчен 3 минут.

2. «Программа» конкурсы:

- Сәләт принципларына туры килү;
- бөтенлек (максатлар һәм бурычлар, аларга ирешү ысуллары, программаның нәтиҗәләре);
- текстның төзеклеге (эчтәлек тулылыгы, грамоталылык);
- актуальлек;
- укытучыларның белем дәрәҗәсе, алар белән смена алдыннан, смена вакытында һәм смена тәмамланганнан соң эшләү;
- адаптивлык и индивидуальләштерү (катнашучыларның яше, смена үткәрелә торган территория үзенчәлекләре һ.б. исәпкә алынган);
- перспективалылык;
- тикшерү мөмкинлеге һәм идарә ителеше (программаны йомгаклау механизмнары);
- тормышка ашыру мөмкинлеге (оештыру мәсьәләләре, куркынычлар исәпкә алынган);
- объективлык (кайтаваз нәтиҗәләре);
- ретроспективалылык (программаны узган елларда үткәрүне анализлау).

Регламент: чыгыш ясау өчен 3 минут, сораулар өчен 3 минут.

**«Ел аланы» номинациясе.**

Номинациядә катнашу өчен мөһим шартлар:

- әлеге номинациядә 2024 елгы җәйге профильле «Сәләт» аланнары катнаша ала (Кушымта 1).

Портфолионы бәяләү критерийлары:

- аланда катнашучыларның республика, ил күләмендә казанышлары;
- гаризалар саны һәм катнашучылар саны бәйләнеше;
- алан эшчәнлегенең социаль челтәрләрдәге үз пабликларында, район, республика, ил ММЧларында яктыртылуы;
- аланның профиль һәм тематик эшчәнлеген ел дәвамында алып бару;
- аланның 2023-2024 нче елларда ирешкән уңышлары;
- эшчәнлекнең Сәләт җитәкчелеге тарафыннан бәяләнүе.

Икенче этапта экспертларның бәя бирү критерийлары:

1. «Үзпрезентация» конкурсы:

- презентациянең оригинальлеге;
- презентациянең эчтәлеге (презентациядә берләшмәнең эшчәнлегендә актив катнашу, берләшмә кысаларында һәм аннан тыш казанышлар, җитәкчелек тарафыннан эшчәнлекне бәяләү кебек моментларны чагылдыру);
- презентациянең төзеклеге: видео/фото материаллар, сценография;
- команданың презентациядә катнашуы;
- гомуми тәэсир;
- аланда татар телле мохит булдыру өчен кулланылган ысуллар һәм чаралар;
- аланының уку-укыту, мәдәни һәм спорт программаларында аның профиленең чагылышы;
- балалар белән эшләүдә яңа практикалар булдыру;
- эшчәнлеккә сменада катнашучы балалар һәм аларның әти-әниләре бәяләмәсе;
- лагерьның брендингы (лого, постлар стиле, раздатка, базаны бизәү);
- лагерьның эшчәнлеген социаль челтәрләрдә үз пабликларында яктырту.

Регламент: чыгыш ясау өчен 7 минут, сораулар өчен 3 минут.

**«Ел сәлкеше» номинациясе.**

Номинациядә катнашу өчен мөһим шартлар:

- әлеге номинациядә 14 - 18 яшь аралыгындагы Сәләт хәрәкәтендә активлыгы 2 елдан да ким булмаган, 2024 елгы җәйге профильле «Сәләт» аланнарының сәлкешләре катнаша ала (Кушымта 1);
- һәрбер катнашучыга «Мин - сәлкеш» темасына видео яздырып, аны үзенең социаль челтәрләренә кую зарури.

Видео өчен критерийлар:

- видео вертикаль форматта яздырыла, озынлыгы 40 секундтан артык һәм 1 минуттан ким булырга тиеш;
- видео татар телендә булырга тиеш;
- видеоны ВК яисә Telegram социаль челтәрләрендә куярга мөмкин, текстта #сәләт #сәмрухелпремиясе #молодежьтатарстана хештегларын кулланырга кирәк.

Портфолионы бәяләү критерийлары:

- Сәләт берләшмәсе эшчәнлегендә актив катнашу;
- Сәләт берләшмәсендә казанышларга ия булу;
- шәхси һәм профессиональ уңышларга ия булу;
- фәнни-тикшеренү эшчәнлегендә, мәдәни һәм спорт чараларында, иҗтимагый эшчәнлектә казанышларга ия булу;
- эшчәнлекнең әйдаманнар һәм смена директоры тарафыннан бәяләнүе.

Икенче этапта экспертларның бәя бирү критерийлары:

1. «Үзпрезентация» конкурсы:
- презентациянең оригинальлеге;
- презентациянең эчтәлеге (презентациядә берләшмәнең эшчәнлегендә актив катнашу, берләшмә кысаларында һәм аннан тыш казанышлар, җитәкчелек тарафыннан эшчәнлекне бәяләү кебек моментларны чагылдыру);
- презентациянең төзеклеге: видео/фото материаллар, сценография;
- тамашачыларга мәгълүматны җиткерә белү сәләте;
- гомуми тәэсир;
- Татарстан Республикасы дәүләт телләрен югары дәрәҗәдә белү;
- Сәләт аланнары/проектлары уңышларына өлеш кертү.

Регламент: чыгыш ясау өчен 5 минут, сораулар өчен 3 минут.

2. Интеллектуаль конкурс:
- дөрес җаваплар саны.

**«Ел әйдаманы» номинациясе.**

Әлеге номинациянең лауреатлары һәм җиңүчесе Республикакүләм «Әйдаманнар ярышы 2024» конкурсы нәтиҗәләре нигезендә билгеләнә.

**«Ел клубы» номинациясе.**

Әлеге номинациянең лауреатлары һәм җиңүчесе Төбәк «Сәләт» клублары өчен XX гамәли уку-укыту семинары нәтиҗәләре буенча билгеләнә.

**«Ел кулдашлары» номинациясе.**

Номинациядә катнашу өчен мөһим шартлар:

- әлеге номинациядә 2024 елгы җәйге профильле «Сәләт» аланнарында кулдаш буларак (бер төркемдә) эшләгән әйдаманнар катнаша ала (Кушымта 1).

Портфолионы бәяләү критерийлары (һәр кулдашка бәя бирелә):

- Сәләт берләшмәсендә актив катнашу;
- Сәләт берләшмәсендә алган казанышлары;
- Сәләт берләшмәсенең сменаларында әйдаман буларак актив эшчәнлек алып бару;
- шәхси һәм профессиональ казанышлары;
- фәнни-тикшеренү эшчәнлегендә, мәдәни һәм спорт чараларында, иҗтимагый эшчәнлектә казанышлар;
- эшчәнлекнең сменаның өлкән әйдаман һәм директоры тарафыннан бәяләнүе.

Икенче этапта экспертларның бәя бирү критерийлары:

1. «Үзпрезентация» конкурсы:
- презентациянең оригинальлеге;

- презентациянең эчтәлеге (презентациядә берләшмәнең эшчәнлегендә актив катнашу, берләшмә кысаларында һәм аннан тыш казанышлар, җитәкчелек тарафыннан эшчәнлекне бәяләү кебек моментларны чагылдыру);
- презентациянең төзеклеге: видео/фото материаллар, сценография;
- ике кулдашның да кызыксынуы;
- гомуми тәэсир;
- Татарстан Республикасы дәүләт телләрен югары дәрәҗәдә белү;
- төркемдә эшне формалаштыру һәм оештыру (шәмчекләр, уеннар, төркем вакыты);
- эшчәнлекнең балалар һәм аларның ата-аналары тарафыннан бәяләнүе.

Регламент: чыгыш ясау өчен 5 минут, сораулар өчен 3 минут.

2. «Педагогик очраклар» конкурсы:
   - катлаулы педагогик очраклар барлыкка килгәндә үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен аңлау.

**«Сәләт җырлый» махсус номинациясе.**

Номинациядә катнашу өчен мөһим шартлар:

- әлеге номинациядә 2024 елда Сәләт берләшмәсендә иҗат ителгән автор җырлары катнаша ала;
- җыр Сәләт кыйммәтләрен чагылдырырга һәм аның принципларына туры килергә тиеш.

Җырлар ике этапта бәяләнәчәк: халык тавыш бирүе, аның нәтиҗәсендә берничә финалист билгеләнәчәк, аннары финалистларны коэффициентлар нигезендә экспертлар бәяләячәк: 1,5 – катнашучы җырның сүзләрен һәм көен үзе язган булса, 1 – катнашучы башка автор көенә үз аранжировкасын ясаган һәм җыр сүзләрен үзе язган булса.

Бәяләү өчен критерийлар:

- шигырь текстының сәнгати дәрәҗәсе;
- музыканың оригинальлеге;
- әсәрнең композиция бөтенлеге;
- Сәләт кыйммәтләренең чагылышы.

**«Ел алан укытучысы» махсус номинациясе.**

Бу номинациядә читтән торып катнашу каралган.

Номинациядә катнашу өчен мөһим шартлар:

- әлеге номинациядә 2024 елгы җәйге профильле «Сәләт» аланнарының укытучылары катнаша ала (Кушымта 1).

Портфолионы бәяләү критерийлары:

- Сәләт берләшмәсе эшчәнлегендә актив катнашу;
- Сәләт берләшмәсендә казанышларга ия булу;
- шәхси һәм профессиональ уңышларга ия булу;
- фәнни-тикшеренү эшчәнлегендә, мәдәни һәм спорт чараларында, иҗтимагый эшчәнлектә казанышларга ия булу;
- эшчәнлекнең смена методисты тарафыннан бәяләнүе.

Программаның бәяләү критерийлары:

- Сәләт принципларына туры килү;

- бөтенлек (максатлар һәм бурычлар, аларга ирешү ысуллары, программаның нәтиҗәләре);
- текстның төзеклеге (эчтәлекнең тулылыгы, грамоталылык);
- актуальлек;
- адаптивлык и индивидуальләштерү (катнашучыларның яше, смена үткәрелә торган территория үзенчәлекләре һ.б. исәпкә алынган);
- перспективалылык;
- тикшерү мөмкинлеге һәм идарә ителеше (программаны йомгаклау механизмнары);
- тормышка ашыру мөмкинлеге (оештыру мәсьәләләре, куркынычлар исәпкә алынган);
- объективлык (кайтаваз нәтиҗәләре).

Программаның тексты word форматында (шрифт 12, интервал 1,5) ясала. Текстның күләме 20 биттән артмаска тиеш. Программа мәҗбүри рәвештә төп тезисларны ачыклый торган, фото һәм видео ярдәмендә нәтиҗәлелеген дәлилли торган кушымта белән тулыландырылырга тиеш. Программа шаблоны оештыру комитеты тарафыннан катнашучыларга аерым җибәрелә.

**«Ел форум башҗитәге» махсус номинациясе.**

Бу номинациядә читтән торып катнашу каралган.

Әлеге номинациягә гаризалар кабул ителми. XIII Халыкара «Сәләт» яшьләр уку-укыту форумында катнашкан алан директорларының һәрберсе әлеге номинация катнашучылары булып билгеләнә.

Бәяләү өчен критерийлар:

- алан директоры буларак эшләгән сменалар саны;
- эшчәнлекнең форум оештыру комитеты (мәгълүмати үзәк, программа, аланнар) тарафыннан бәяләнүе;
- эшчәнлекнең «Сәләт» ТТЯФ тарафыннан бәяләнүе;
- эшчәнлекнең әйдаманнар һәм сәлкешләр тарафыннан бәяләнүе.

**«Ел клуб кураторы» махсус номинациясе.**

Бу номинациядә читтән торып катнашу каралган.

Әлеге номинациягә гаризалар кабул ителми. Бер елдан күбрәк үз эшчәнлеген алып барган һәрбер төбәк «Сәләт» клубы кураторы әлеге номинация катнашучысы булып билгеләнә.

Бәяләү өчен критерийлар:

- төбәк «Сәләт» клубы эшчәнлегендә актив катнашу;
- «Сәләт» Клубы эшчәнлегендә актив катнашу;
- кураторның инициативалы булуы;
- кураторның коммуникация дәрәҗәсе;
- кураторның эшчәнлеге дәверендә төбәк «Сәләт» клубының сан күрсәткечләре үзгәрүе динамикасы;
- төбәк «Сәләт» клубының активистлары һәм әгъзалары саны.

**«Ел клуб җитәкчесе» махсус номинациясе.**

Бу номинациядә читтән торып катнашу каралган.

Әлеге номинациягә гаризалар кабул ителми. Бер елдан күбрәк үз эшчәнлеген алып барган һәрбер төбәк «Сәләт» клубы җитәкчесе әлеге номинация катнашучысы булып билгеләнә.

Бәяләү өчен критерийлар:

- төбәк «Сәләт» клубы эшчәнлегендә актив катнашу;
- «Сәләт» Клубы эшчәнлегендә актив катнашу;
- җитәкченең «Сәләт» Клубы күчмә сессияләрендә катнашуы;
- җитәкченең административ сорауларны чишүе;
- җитәкченең инициативалы булуы;
- җитәкченең коммуникация дәрәҗәсе;
- җитәкченең эшчәнлеге дәверендә төбәк «Сәләт» клубының сан күрсәткечләре үзгәрүе динамикасы;
- төбәк «Сәләт» клубының активистлары һәм әгъзалары саны;
- клубның әлеге җитәкче эшчәнлеге вакытында «Ел клубы» номинациясендә катнашуы.

## 6. Премиянең Оештыру комитеты.

Оештыру комитеты Премияне әзерләү һәм уздыру өчен Сәләт активистларыннан, «Сәләт» клубы әгъзаларыннан, «Сәләт» фонды һәм «Сәләт» яшьләр үзәге хезмәткәрләреннән туплана. Оештыру комитетының составы «Сәләт» ТТЯФ генераль директоры тарафыннан раслана.

Оештыру комитеты:

- премияне оештыру әзерлеген уздыра;
- премиянең барлык этапларын әзерләү һәм уздыру стадиясендә административ тәэмин итүне гамәлгә ашыра;
- премия программасының һәр этабын уздыруны билгели һәм раслый, үткәрү вакытын һәм урынын билгели;
- махсус номинацияләр билгели ала.

## 7. Премиянең экспертлар советы.

«Катнашучыларны сайлап алу» этабын оештыру һәм билгеләү өчен Экспертлар советы булдырыла. Аның составы «Сәләт» ТТЯФ генераль директоры тарафыннан раслана.

Экспертлар советы составына Дәүләт органнары хезмәткәрләре, танылган җәмәгать эшлеклеләре, фән, мәгариф, мәдәният хезмәткәрләре керергә мөмкин.

Экспертлар советы беренче этапта кабул ителгән конкурс материалларын бәяли. Катнашучыларны әңгәмә нигезендә сайлап алу этабында конкурсантка бәя бирә һәм премиянең җиңүчесен билгели.

Экспертлар советы өстәмә рәвештә махсус бүләкләр һәм номинацияләр билгели ала.

8. Гариза тутыруга таләпләр.

Катнашучының гаризасы портфолио һәм гариза битеннән гыйбарәт. Гариза формасы www.selet.biz сайтында тутырыла. Гаризада күрсәтелмәгән һәм портфолиода документлар белән расланмаган мәгълүмат исәпкә алынмый.

Портфолионың эчтәлеге:

- дипломнар, рәхмәт хатлары, грамоталар, мактау грамоталары, сертификатлар;
- иллюстрацияләр (фотосурәтләр, басма массакүләм мәгълүмат чараларыннан копияләр, видеоматериаллар һ.б.);
- тәкъдим итү хатлары;
- соңгы ике ел эчендә ирешкән уңышларны раслаучы башка документлар.

Формаль шартлар:

- катнашучының уңышларын раслаучы документлар (дипломнар, рәхмәт хатлары, басма матбугат чараларында чыккан язмалар) электрон рәвештә (копия яки сыйфатлы фото) бер файлда тапшырылырга тиеш, портфолио шаблоннары оештыру комитеты тарафыннан катнашучыларга аерым җибәрелә;
- иллюстрацион материаллар, гаризалар (фото һәм видео) электрон форматта документлар белән бер файлда бирелергә тиеш.

9. Гаризаны тапшыру тәртибе.

Гариза тапшыру вакыты **2024 елның 20 нче ноябреннән** дә соңрак булырга тиеш түгел.

Премиядә катнашу өчен портфолио электрон форматта оештыру комитетына тапшырыла. Портфолио шаблоннары оештыру комитеты тарафыннан катнашучыларга аерым җибәрелә. Белешмәләр өчен телефон: + 7 (843) 292-16-00.

Әлеге нигезләмәгә туры килмәгән гаризалар конкурста каралмый.

Гаризалар саны аз булган очракта, Оештыру комитеты гаризалар кабул итү этабын озайта ала яки кайсыдыр номинациядә ярыш уздырылмаска мөмкин.

10. Фестивальдә катнашучыларның шәхси белешмәләрен эшкәртү һәм яклау.

Оештыручыларга тапшырыла торган мәгълүмат шәхси мәгълүмат булып санала һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә саклана.

Республикакүләм премиядә катнашып, катнашучы Россия Федерациясенең 2006 елның 27 июлендәге 152 номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы федераль законы нигезендә оештыру турында мәгълүмат җиткерү һәм шундый ук чараларда катнашу максатында үзенең шәхси мәгълүматларын автоматлаштырылган һәм автоматлаштырылмаган эшкәртүгә ризалыгын бирә, шул исәптән: фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу датасы, телефон номеры, электрон почта адресы, эшләү/уку урыны, ил, төбәк, шәһәр. Премиядә җиңү яулаган очракта, күрсәтелгән шәхси мәгълүматлар Оештыручылар яки әлеге премияне уздыру белән бәйле рәвештә конфиденциаль мәгълүматларны таратмау турындагы килешүләр нигезендә эш итүче вәкаләтле затлар тарафыннан гына кулланылачак һәм әлеге премиягә бәйле рәвештә бернинди өченче затларга да бирелмәячәк. Дәүләт ярдәме күрсәтү нияте белән Оештыручы катнашучылар турында мәгълүматны  башка оештыручыларга тапшыра ала.

Премиядә катнашучыларның шәхси мәгълүматларын эшкәрткәндә оештыручылар Россия Федерациясенең 2006 елның 27 июлендәге 152 номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында» федераль законы белән җитәкчелек итә. Оештыручылар шәхси мәгълүматны саклау өчен кирәкле оештыру һәм техник чаралары булдыра.

Тиешле язма документны Оештыручы һәм Оештыручы адресына хат юллау яисә Оештыручыларга һәм Оештыручыларның вәкилләренә шәхсән тапшыру юлы белән шәхси мәгълүматларны эшкәртү процессы туктатылырга мөмкин.

Кушымта 1.

**2024 елгы җәйге профильле «Сәләт» аланнары исемлеге**

1. «Сәләт — Адымнар»
2. «Сәләт — Олимп»
3. «Сәләт — Биләр каласы»
4. «Сәләт — Санак»
5. «Сәләт — Акбүре»
6. «Сәләт — Иманкәй»
7. «Сәләт — Тел»
8. «Сәләт — Раушан»
9. «Сәләт — Алмаз»
10. «Сәләт — Шәхес»
11. «Сәләт — Манзара»
12. «Сәләт — Рухият»
13. «Сәләт — Мирас»
14. «Сәләт — Кама»
15. «Сәләт — Алмагач»
16. «Сәләт — Осталар бистәсе»
17. «Сәләт — Батыр»
18. «Сәләт — Җисем»
19. «Сәләт — Гайрәт»
20. «Сәләт — Илем»
21. «Сәләт — Саба»
22. «Сәләт — Азнакай»
23. «Сәләт — Тулпар»
24. «Сәләт — Галәм»
25. «Сәләт — Аршан»